РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
НИЖНЕШИТЦИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422067, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15 йорт
тел. (84362) 46-4-42

e-mail: shic.sab@tatar.ru

15.06.2020 № 14

РЕШЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Түбән Шытсу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул иткән көннән соң «Саба таннары» газетасында биш көннән дә соңга калмыйча бастырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов